Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга  авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга авылы  торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ  КАРАРЫ

2019  елның  7 нче ноябре № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль  законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының  35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы  Югары Ырга  авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга  торак пунктында гражданнар җыены  **КАРАР БИРӘ**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль  районы Югары Ырга  авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга  торак пунктында тору урыны буенча  теркәлгән  балигъ  булган  һәр кешесеннән, уку йортларына йөреп (көндезге бүлектә) укучы студентлардан   гайре,  500 сум күләмендә үзара салым  акчасы кертергә.
2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

- энергия саклаучы урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру;
- авыл җирлеге торак пунктларында юл кырыйларында чүп үләннәрен чабу
- Яңа Ырга авылындагы Мәктәп һәм Ворошилов урамнарындагы юлларны ремонтлау;
-Югары Ырга авылы М. Җәлил урамы буенча вак таш катламы җәю;
- авыл җирлеге торак пунктларында юлларны кышкы карап тоту;
- су белән тәэмин итү

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат  стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18  йорт; Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 йорт; һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы  үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен  җибәрергә.

Гражданнар  җыенында рәислек итүче,

Югары Ырга  авыл җирлеге  башлыгы Р.Н.Багаутдинов